ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.02.2021 Казан шәһәре № 13-2/т-2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пассажирлар йөртүнең даими муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 20 декабрендәге 7-13/т номерлы карары кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пассажирлар йөртүнең даими муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 20 декабрендәге 7-13/т номерлы карары кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
2019 елның 20 декабрендәге
7-13/т номерлы карарына кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
№ _______ ____________________
карары редакциясендә)

## Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә пассажирлар йөртүнең даими муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| Транспорт төре | Бер тапкыр бару һәм бер урынлы багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Бер тапкыр бирелә торган билет сатып алганда | | Электрон юл билеты (транспорт картасы) белән түләгәндә | |
| | акчалата исәп-хисап | акчасыз исәп-хисап[1] | 1 тапкыр бару[2] | 100 тапкыр бару[3] |
| Автобус | 35 | 30 | 27 | 20 |
| Троллейбус | 35 | 30 | 27 | 20 |
| Трамвай | 35 | 30 | 27 | 20 |

<1> түләү (банк) карталары (транспорт кушымтасыннан башка) яки бәйләнешсез түләү технологиясе булган башка электрон түләү чаралары ярдәмендә;

<2> юлда барган өчен теркәлгән сумма чикләрендә һәм транспорт кушымтасы булган банк карталары белән түләү хокукын бирә торган, озак файдаланыла торган билетлар ярдәмендә түләгәндә;

<3> күрсәтелгән вакыт эчендә юл өчен саны билгеләнгәнчә бару хокукын бирә торган озак файдаланудагы билетлар белән түләгәндә.

Искәрмә. Багаж алып бару бәясе юл йөрү бәясеннән аерым түләнә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге